ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.12.2021 г.Лениногорск № 1142

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 09 августындагы 728 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларына өстәмәләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 18 сентябрендәге 1574 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Кертергә:

Территорияне планлаштыру буенча документларны яңа редакциядә әзерләү һәм раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан читләштерүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Ана (гаилә) капиталы средстволарын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкаруны тикшерү актын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Капиталь төзелеш объектын сүтү планлаштырыла торган хәбәрнамә һәм капиталь төзелеш объектын сүтү тәмамлануы турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше йөзен килештерү турында карар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Индивидуаль торак төзелеше объекты яисә бакча йорты параметрларының билгеләнгән параметрларына һәм индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объектын җир кишәрлегендә урнаштыруның мөмкин булуы турында хәбәр итү юнәлешендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты төзелгән яисә реконструкцияләнгән объектның шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәр итү юнәлеше буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты параметрлары планлаштырыла торган төзелеш турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларның билгеләнгән параметрларга туры килүе һәм җир кишәрлегендә индивидуаль торак төзелеше объектын яки бакча йортын урнаштыру мөмкинлеге турында хәбәрнамә юлламасы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Төзелгән яисә үзгәртеп корылган индивидуаль торак төзелеше объектының яки бакча йортының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар таләпләренә туры килүе турында хәбәрнамә җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Агач, куаклар кисүгә, кронлаштыруга, утыртуга, газонны сүтүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Проект документациясен, эшләрне җитештерү проектын һәм инженер-топография планын килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты;

Реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә, элек бирелгән рөхсәтләрне юкка чыгаруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

2.16.1 пунктны пунктчалар белән тулыландырырга:

«ж) органга (оешмага) кабул итүгә язылу, хезмәт күрсәтү турында запрос бирү өчен (алга таба-запрос) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба-күпфункцияле үзәк), шулай ук хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган очракларда, әлеге запросны күрсәтелгән кабул итүгә бер үк вакытта язылып, бирү мөмкинлеге; (үз көченә 2022 елның 22 мартыннан керә)

з) муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентында каралган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын билгеләү максатларында, мөрәҗәгать итүченең билгеләренә туры килә торган анкеталаштыру (мөрәҗәгать итүчегә сораулар исеемлеген һәм аларга тулы җаваплар вариантлары исемлеген күрсәтү);

и) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында каралган муниципаль хезмәт күрсәтү вариантын күрсәтү.».

2. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорскские вести» газетасында бастырырга, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет - сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар күзәтү өчен мөмкин булган мәгълүмат стендларында урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Г.А. Иванова

Л.М.Галимова
5-21-21